**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.12.2025 **Чирмешән авылы** **№ 422**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Хезмәтне саклау буенча Координация советы составын һәм нигезләмәне раслау турында»2012 елның 18 декабрендәге 734 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (210 маддә), «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 10.12.1997 №1417 Татарстан Республикасы Законы таләпләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 10.11.2008 ел, №799 карары нигезендә, Татарстан Республикасында Чирмешән муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә гражданнарның социаль-хезмәт хокукларын гамәлгә ашыру, аны яхшырту эшен камилләштерү максатларында *(19.08.2013 ел, №468а, 04.07.2014 ел, №399, 16.02.2016 ел №110, 23.03.2016 ел, №175, 25.10.2023 ел, №306, 23.12.2024 ел, №435 үзгәрешләре белән),* кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Хезмәтне саклау буенча Координация советы составын һәм нигезләмәне раслау турында» 18.12.2012 ел, №734 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы составына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Г. Мортазинага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе                                                                                              И.М. Җамалетдинов

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 24 декабрендәге
422 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты каршындагы хезмәтне саклау буенча
Координация советы составы

| | |
|---|---|
| Координация советы рәисе<br><br>Мортазина Лилия Габдрауф кызы | <br><br>Чирмешән муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Координация советы рәисе урынбасары<br><br>Вильданов Муса Габделхак улы | <br><br>Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Координация советы секретаре<br><br>Исмендеева Ирина Петровна | <br><br>Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы |
| Координация советы әгъзалары | |
| Әхмәдуллина Рушания Солтан кызы | Татарстан Республикасы мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Чирмешән муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Бадыгина Гүзәл Әмер кызы | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Нурлат, Аксубай, Әлки, Чирмешән районнарында (Нурлат территоиаль бүлеге) идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Вафина Гөлназ Вәлиҗан кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Чирмешән районы буенча җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Ганеев Ринат Габделхәй улы | Ростехнадзорның Идел буе идарәсенең Көньяк-Көнчыгыш территориаль бүлеге дәүләт инспекторы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гарифов Владимир Александрович | РФ Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең Лениногорск районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гатина Лилия Сәүбән кызы | Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү Фондының Татарстан Республикасы бүлекчәсенең Чирмешән районындагы клиент хезмәте җитәкчесе (бүлек хокукларында) (килешү буенча) |
| Җиһаншина Эльвира Борындай кызы | Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Кузнецова Оксана Вячеславовна | «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУның Чирмешән районы буенча бүлек башлыгы (килешү буенча) |
| Малая Ләйсән Әмин кызы | «Чирмешән муниципаль районының гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мордвинов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелегенең Чирмешән муниципаль районы буенча идарәсенең бүлек башлыгы – баш дәүләт инженер-инспекторы |
| Муксинова Ләйгөл Вәгыйз кызы | профсоюз оешмаларының Координация Советы рәисе (килешү буенча) |
| Мөхәммәтгатин Илдус Хәниф улы | «Чирмешән районы коммуналь челтәрләре» МУП директоры (килешү буенча) |
| Назыйров Радик Равил улы | Чирмешән районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Пешков Иван Николаевич | Россия Эчке эшләр министрлыгының Чирмешән районы буенча бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Рунова Татьяна Викторовна | Чирмешән муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы |
| Сабирова Эльмира Камил кызы | «Чирмешән үзәк район хастаханәсе» ДАССУның хезмәтне саклау буенча белгече (килешү буенча) |
| Севастьянова Светлана Ильинична | Гомумроссия мәгариф профсоюзының Чирмешән территориаль оешмасы рәисе (килешү буенча) |

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 24 декабрендәге
422 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Чирмешән муниципаль районында**
**хезмәтне саклау буенча Координация советы турында**
**НГЕЗЛӘМӘ**

1. Чирмешән муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы (алга таба - Координация советы) хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм район территориясендә хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау буенча муниципаль программаны гамәлгә ашыру максатларында төзелә.

2. Координация советы үз эшчәнлеген җирле үзидарә органнарының эш бирүчеләр, хезмәтне саклау хезмәтләре, оешмалар, хезмәтне саклау, күзәтчелек һәм контроль өлкәсендә дәүләт идарәсе органнары, Татарстан Республикасында РФ пенсия һәм социаль иминләштерү фонды, профсоюзлар берләшмәләре һәм башка иҗтимагый оешмалар белән сәламәт һәм имин хезмәт шартлары тудыруда үзара хезмәттәшлегендә алып бара.

3. Координация советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларына, хезмәтне саклау өлкәсендәге муниципаль норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Координация советының төп бурычлары булып тора:
- хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләү;
- эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау таләпләрен үтәвен тикшереп тору;
- хезмәткәрләрнең имин шартларга һәм эш урыннарында хезмәтне саклауга хокукларын яклау;
- милекнең төрле рәвешләрендәге оешмаларда хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның гамәлдәге торышын анализлау һәм аларны яхшырту буенча чаралар күрү;
- хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча территориаль программалар эшләү;
- оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүче оешмалар, фәнни оешмалар, медицина учреждениеләре, хезмәтне саклау буенча уку үзәкләре вәкилләре катнашында семинарлар, киңәшмәләр, "түгәрәк өстәлләр", "хезмәтне саклау көннәре", шулай ук хезмәтне саклау буенча башка чаралар үткәрү;
- барлык оештыру-хокукый һәм милек рәвешләрендәге оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга смотр-конкурслар үткәрү;

- хезмәткәрләрнең предприятиеләрдә имин һәм сәламәт хезмәт шартларына хокукларын яклауны тәэмин итү.

5. Координация советы үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

- район территориясендә хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча гамәлдәге законнарны гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне карый;
- хезмәтне саклау шартларын яхшырту буенча территориаль программалар эшләү өчен эшче төркемнәр төзи;
- хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программаларны гамәлгә ашыруны тикшереп тора;
- Координация советы әгъзалары тарафыннан хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау торышын өйрәнү һәм анализлау, аларны яхшырту буенча чаралар күрү максатларында төрле милек рәвешләрендәге оешмаларга баруны планлаштыра;
- эш бирүчеләрнең хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары белән авыр эшләгәннәре өчен компенсация бирүнең дөреслеге мәсьәләләрен карый;
- барлык оештыру-хокукый һәм милек рәвешләрендәге оешмаларның хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга смотр-конкурсларда катнашуын оештыра;
- барлык оештыру-хокукый һәм милек рәвешләрендәге оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларын иң яхшы оештыруга смотр-конкурсларда җиңүчеләрне билгели;
- хезмәтне саклау һәм җитештерү санитариясе өлкәсендә профилактик эшнең алдынгы ысулларын һәм формаларын кертү мәсьәләләре буенча оешмаларга ярдәм итә;
- 50 кешедән артык эшләүче оешмаларда хезмәтне саклау хезмәтләре оештыруга ярдәм итә;
- төркемле бәхетсезлек очракларының, үлемгә китергән бәхетсезлек очракларының сәбәпләрен карый һәм аларны бетерү буенча чаралар күрә;
- производствода имгәнүләр, аварияләр һәм һөнәри авырулар саны артуга юл куйган яисә югары дәрәҗәдә булган оешмаларда күзәтчелек һәм контроль органнары үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләрен карый;
- хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация үткәрүне активлаштыруга, аннан соң барлык милек рәвешләрендәге оешмаларда хезмәтне саклау эшләрен сертификацияләүгә ярдәм итә;
- үз утырышларында эш бирүчеләрне производствода имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны кисәтү, эш урыннарында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча күрелә торган чаралар турында тыңлый;
- Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, прокуратура, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор органнарына, башка күзәтчелек һәм контроль органнарына хезмәтне саклау турындагы закон таләпләрен бозган эш бирүчеләргә карата чаралар күрү турында, производствода имгәнүләр һәм һөнәри авырулар санының югары дәрәҗәсе турында тәкъдимнәр кертә;
- оешмаларда хезмәтне саклау буенча күмәк шартнамәләр һәм килешүләр төзү, хезмәтне саклау буенча җитәкчеләрне һәм белгечләрне укыту, эшләүчеләрне махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка индивидуаль яклау чаралары белән тәэмин итү буенча агымдагы эшләрнең торышын карый;

- хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча үзебезнең һәм чит илләрнең алдынгы эш тәҗрибәсен таратуга ярдәм итә.

6. Координация советы рәисе булып Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади мәсьәләләр буенча урынбасары тора.

7. Координация советы составы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана. Координация советында эшләргә кирәк булганда квалификацияле белгечләр җәлеп ителә.

8. Координация советы үз эшчәнлеген Координация советы утырышында кабул ителә торган эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

9. Координацион совет утырышында аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

10. Координацион совет утырышлары кварталга кимендә 1 мәртәбә уздырыла.

11. Координация Советы карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен утырышта катнашучы Координация советы әгъзаларының яртысыннан артыграгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәиснең тавышы хәлиткеч була.

12. Координация советы утырышлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга рәис һәм секретарь кул куя.